# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# «ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

«30» май 2016 ел № 7/6

**Тукай муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү өчен муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2011 елның 21 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Т муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү өчен муниципаль мөлкәт исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Тукай районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев